**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
ЧЕРЕМШАНСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
**СОВЕТ**
**СТАРОУТЯМЫШСКОГО**
**СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**

423105,Черемшанский район, с.Старый
Утямыш, ул.Мусы Джалиля, дом 52

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
**ИСКЕ ҮТӘМЕШ АВЫЛ**
**ҖИРЛЕГЕ**
**СОВЕТЫ**

423105,Чирмешән районы Иске Үтәмеш
авылы, Муса Җәлил урамы, 52 нче йорт

тел./факс 8-84396-2-37-16 email: Sut.Cmn2@tatar.ru

**15 декабрь 2025 ел** **№ 11**

# Татарстан Республикасы
# Чирмешән муниципаль районының
# Иске Үтәмеш авыл җирлеге Советы
# КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Иске Үтәмеш авыл җирлеге Советының «Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Иске Үтәмеш авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 27 апрелендәге 73 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең, рәис урынбасарларының, аудиторларының, Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәтенә түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2025 елның 25 ноябрендәге 994 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Иске Үтәмеш авыл җирлеге Советы **КАРАР КЫЛДЫ:**

1. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Иске Үтәмеш авыл җирлеге Советының «Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Иске Үтәмеш авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 25 апрелендәге 79 номерлы карарына (җирлек Советының 2018 елның 24 августындагы № 90, 2018 елның 16 ноябрендәге № 94,

2020 елның 14 октябрендәге № 7, 2022 елның 20октябрендәге  № 70, 2023 елның 31 гыйнварындагы № 80, 2024 елның 20 июнендәге № 129, 2024 елның 26 декабрендәге № 158, 2025 елның 30 апрелендәге № 162 карары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1 өлешнең 3 абзацын бәян итәргә: «Иске Үтәмеш авыл җирлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларының кече төркеме белгеченең вазыйфаи окладының күләме 16928,0 сум тәшкил итә»;

1.2. «Авыл җирлегендә үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы авыл җирлеге башлыгына айлык акчалата түләү күләмнәре» 3 нче кушымтасын яңа редакциядә кушымтада каралганча бәян итәргә.

2. Әлеге карарны хокукый мәгълүматның рәсми порталында бастырып чыгарырга (pravo.tatarstan.ru) һәм Интернет челтәрендә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2026 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

ТР Чирмешән муниципаль районы
Иске Үтәмеш авыл җирлеге
башлыгы, Совет рәисе                                        Р.С.Мингулов

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
Иске Үтәмеш авыл җирлеге Советының
2025 елның 15 декабрендәге
№ 11 карарына
кушымта

Авыл җирлегендә үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы
авыл җирлеге башлыгына айлык акчалата түләү күләмнәре

| Вазыйфалар атамасы | Акчалата бүләкләү күләме (сумнарда) |
|---|---|
| Җирлек башлыгы | 23201,0 |